РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г.
Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт,
Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 31 мае № 22

Түбән Кама шәһәр Советының 2021 елның 26 гыйнварындагы «Инициативалы проектлар турында» 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 26.1 һәм 56.1 статьялары нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2021 елның 26 гыйнварындагы «Инициативалы проектлар турында» 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу, карау, шулай ук аларны конкурс нигезендә сайлап алуны уздыру тәртибенең 3.5 пунктында «Башкарма комитетка» сүзләрен «башка муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы яисә дәүләт органының үз компетенцияләре нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын үстерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р.Метшин